НӘФРӘТТӘН – МӘХӘББӘТКӘ

Исәнбай мәктәбе укучысы Камилә Ганиева химиядән 100 балл җыйган

> 2

НАИЛ ШӘРИФУЛЛИН:

«Без бөек, без «иң-иң»нәр, дия-дия, фәнне шактый түбән төшердек

> 2

ЧИГҮЛЕ ТАТАРСТАН

Республика картасын энә һәм җеп белән дә төшереп була

> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 82 (29049) | Шимбә | 10 июнь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

АЧЫК ТӘРӘЗӘ

Борчыган мәсьәлә

Быелгы җәй Алабугада яшәүче яшь гаилә өчен коточкыч фаҗигадән башланган. Әнисе кер юып йөргәндә, өч яшьлек кызлары тәрәзәдән егылып төшеп үлгән. Беренче июнь көнне Казанда да шундый фаҗигадә ике яшьлек баланың гомере өзелә. Түбән Камада бишенче кат балконыннан егылып төшкән дүрт яшьлек бала, бәхеткә, исән кала. Кызганыч, быелгы җәй әнә шундый хәбәрләре белән тетрәндерде.

Белгечләр чаң суга! Сугарлык та. Җәй башланырга да өлгермәде, Татарстанда инде тәрәзәдән егылып төшү аркасында өч бала зыян күрде. Бу бәхетсезлек очракларына, нигездә, ата-ананың игътибарсызлыгы, ваемсызлыгы сәбәпче, ди белгечләр. Ата-аналар исә бу фикер белән бик килешеп бетми.

Казанда яшәүче танылган блогер, өч кыз үстерүче Айгөл Темирбулатова фикеренчә, гаеп атта да, тәртәдә дә.

– Әти-әниләрне җавапсызлыкта гаеплисе килми. Балалар да бик шук бит хәзер. Дөрес, шәхсән үземнең күңелемә ятып бетмәгән бер күренеш бар. Күп әти-әни, кечкенә баланы нәрсә белән булса да мавыктыру өчен, аны тәрәзә төбенә бастырып, урам күрсәтә. Бу – бик зур хата. Ник дигәндә, бала моны шулай тиеш дип кабул итә башлый, – ди Айгөл. – Безнең тәрәзәдә махсус җайланмалар юк. Москит челтәре дә куймадык. Әмма бүлмәләрне җилләткәндә тәрәзәләрне беркайчан да төбенә кадәр ачып куйганыбыз юк. Безнең балалар ул кагыйдәләрне белә. Бездә тәрәзә төбенә басарга, тәрәзәне ачарга ярамый. Кызларыбыз шук түгел, сүз тыңлый. Шуңа ул яктан безгә җиңелрәк.

Республика клиник балалар хастаханәсенең хирургия ярдәме буенча баш табиб урынбасары Михаил Поспелов сүзләренә караганда, ел башыннан бирле Татарстанда барлыгы 14 бала тәрәзәдән егылып төшкән. Өчесенең гомере өзелгән. Араларында кечкенә балалар гына түгел, үзенең ни эшләгәнен белештерерлек 12 яшьлек бала да бар. Поспелов сүзләренә караганда, тәрәзәдән егылып төшкән балаларның, нигездә, баш сөягенә, аяк-кулларына, баш миенә зыян килә. Умыртка баганасы сынучылар да шактый. Эчке органнарга кан саву очраклары да бар.

– Кызганыч, мондый фаҗигадән соң могҗизага өметләнүдән файда юк. Шәхсән үземнең эш тәҗрибәмдә шундый бер очрак кына булды. 2001 елда 9 нчы кат тәрәзәсеннән егылып төшкән бала исән калды. Ул гына да түгел, егылу аркасында баланың нибары тешләре генә сынган иде, – дип искә ала табиб. – Мондый фаҗигаләрне кисәтү тулысынча ата-ана җилкәсендә. Кечкенә баланың бар нәрсәне эшләп, капшап, тотып карыйсы килә бит. Шуңа күрә балаларны өйдә үзләрен генә калдырырга ярамый. Абый-апалары белән генә калдыру да куркыныч. Ник дигәндә, алар еш кына гаджетларда утыра, балада гамьнәре булмый. Тәрәзә яннарында урындык, өстәл кебек җиһазлар да тормаска тиеш. Алар ярдәмендә бала тәрәзә төбенә җайлы гына менә ала. Аннары ата-ана шуны да онытмасын иде: тәрәзәгә куелган москит челтәре егылудан сакламый, чебен-черкидән генә коткара. Шуңа күрә тәрәзәгә чикләгеч яки йозак куюдан да яхшысы юк.

Чикләгеч дигәннән, Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец яңа төзелгән һәр йорт тәрәзәсендә шундый җайланма булырга тиеш дип саный.

– Кулланылышка тапшырылган һәр йортта шундый җайланма булырга тиеш. Төзүчеләргә шундый таләп куярга кирәк. Әлеге тәкъдимне Россия Төзелеш министрлыгына да юлладым. Ә вазгыять катлауланганнан-катлаулана бара. Иске йортларда яшәүчеләр мондый җиһазларны үзләре куярга тиеш. Аз керемле гаиләләргә чикләгеч җайланмаларны бушлай кую өчен махсус дәүләт программасы да эшләргә була. Татарстан Дәүләт Советына шундый тәкъдим юлларга җыенабыз. Моның өчен ата-аналар да җаваплы, билгеле. Балалар саны болай да бик аз. Ә без булганнарын да саклый алмыйбыз, – ди омбудсмен.

Бер уйласаң, моның өчен әллә ни күп тә кирәк түгел кебек. Уяулыкны югалтмыйча, иң беренче чиратта, балаңа тәрәзә янына барырга ярамаганлыгын аңлатырга, аның үзен генә калдырмаска кирәк, ди белгечләр. Тәрәзәгә чикләгеч җайланма куюның да бер авырлыгы да юк ләбаса! 130–300 сум чамасы торган әлеге җайланманың бәясен дә бала гомере белән чагыштырырлык түгел.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мондый фаҗигане булдырмас өчен түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга кирәк, ди белгечләр.

➤Бала андый фаҗигагә ата-ана өйдә юк чакта ешрак очрый. Кечкенә балаларны игътибарсыз калдырмагыз.

➤Москит челтәренә ышанмагыз. Ул, киресенчә, фаҗигагә этәрә генә. Күп очракта балалар нәкъ менә шушы сетка белән бергә очып төшә.

➤Тәрәзә янында бернинди җиһаз тормасын, бала менәрлек булмасын.

➤Тәрәзәне өске якка каратып ачарга тырышыгыз.

➤Тәрәзәне берничә сантиметр гына ачарлык итеп чикләгеч куегыз.

➤Тәрәзәгә рәшәткәләр куйсагыз да, җаныгыз тыныч булыр.

➤Балага тәрәзәдән егылып төшү хакында еш сөйләп, кат-кат кисәтеп торыгыз.

Фикер

Регина ФӘХРИСЛАМОВА, педагог-психолог, балалар психологы:

– Замана ата-аналарының күбесе үз тормышы, үз үсеше белән мәшгуль. Шул сәбәпле күп кенә гаиләләрдә бала үз-үзенә тапшырылган була. Мондый фаҗигаләр саны артуга, иң беренче чиратта, әнә шул сәбәпче. Аннары ата-аналарның күбесе бала психологиясен белеп бетерми. Бу да мондый фаҗигаләр килеп чыгу ихтималын бермә-бер арттыра. Өч яшьтән башлап 5–6 яшькә кадәр бала «ярый-ярамый»ларны сеңдереп үсә. Бу чорда аңа бөтен куркынычсызлык кагыйдәләрен төшенгәнче аңлатырга, өйрәтергә кирәк. Әмма бала бу чорда бар нәрсәне эшләп карау теләге белән яна. Шуңа күрә кагыйдәләрне белә дип кенә тынычланырга ярамый. Бала тугыз яшьләрендә генә үлемнең нәрсә икәнен аңлый, аннан курка башлый. Бу чорга кадәр ата-анага аеруча уяу булырга кирәк.

РОССИЯ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Россия көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле татарстанлылар!

Сезне дәүләт бәйрәме – Россия көне уңаеннан чын күңелдән тәбрик итәм. Ул Ватанга мәхәббәт һәм тугрылык, ата-бабаларыбызга, илебез тарихына ихтирамлы мөнәсәбәт, үткәндәге, шулай ук бүгенге көндәге хезмәт һәм сугыш батырлыклары символы булып тора.

Россия – чын мәгънәсендә, яу кырында һәм тыныч тормышта һәрчак илебез мәнфәгатьләрен якларга әзер булган батырлар ватаны. Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрнең кыюлыгы, каһарманлыгы һәм фидакарьлеге – моның ачык дәлиле. Бүген, Россиянең суверенлыгы һәм киләчәге өчен көрәш барган шартларда, күпмилләтле халкыбыз, бердәм булып, заман сынауларына каршы тора. Безне уртак язмыш берләштерә һәм үз туган җиребездә барлык авырлыкларны да җиңеп чыгачакбыз. Безнең рухыбызны сындыра алмаслар!

Россия фән һәм мәгариф, сәнгать һәм спорт, медицина өлкәләрендә, биотехнологияләр, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, цифрлаштыру тармакларында һәм космосны үзләштерүдә олы казанышлары белән дан тота.

Илебез гүзәл табигате, үзенчәлекле архитектурасы һәм төзелеш сәнгате ядкарьләре, күпгасырлык мәдәнияте һәм традицияләре, кунакчыл һәм киң күңелле кешеләре белән бөтен дөнья халкын үзенә җәлеп итә.

Быел Татарстанда уздырылган «Россия – ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый форумы, 2024 елда Казанда уздырылачак БРИКС илләре башлыклары очрашуы Россиянең ышанычлы партнерлары һәм дусларының күп булуын раслый.

Татарстан Республикасы, Федерациянең төп субъектларыннан берсе буларак, Россиянең куәтен ныгытуга саллы өлеш кертә. Нефть-газ-химия комплексы, машина төзелеше, авыл хуҗалыгы республика икътисадының нигезен тәшкил итә. Бездә самолетлар, вертолетлар, КАМАЗ базасында техника һәм бронялы автомобильләр, хәрби кораблар һәм катерлар, радиоэлектрон аппаратура, оптика, дары һәм Ватаныбызның оборона мөмкинлекләрен тәэмин итү өчен коралланудың башка төрләре җитештерелә. «Алабуга» һәм «Иннополис» махсус икътисадый зоналары, ИТ һәм технопарклар технологияләр һәм инновацияләр үсешенә этәргеч бирүче чыганаклар булып тора. Иң мөһиме, ирешкән казанышларыбыз – үз һөнәренә тугры кешеләрнең тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Шул ук вакытта без барлык эшләребездә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең һәм шәхсән Россия Федерациясе Президенты, илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путинның ныклы ышанычын һәм ярдәмен тоябыз.

Кадерле татарстанлылар!

Россия көнен бәйрәм итү сезгә яңа җиңүләр һәм уңышларга ирешүдә бәрәкәтле көч биреп, игелекле гамәлләргә рухландырыр, гражданнар бердәмлеге үрнәге булып торыр, дип ышанам.

Илебезгә һәм аның күпмилләтле халкына иминлек һәм зур үсеш телим. Россия, алга!

Киңәш-табыш

Салым серләре

Мәгълүм булганча, май аенда Президент имзалаган закон нигезендә, ике һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә җир кишәрлеген һәм анда урнашкан хуҗалык корылмасын сатканда салым түләүдән азат иттеләр. Гаиләләргә тагын нинди салым ташламалары каралган? Шул хакта искә төшерәбез.

✓Ике һәм аннан да күбрәк балалары булган кешеләр торак сатудан килгән керемнән НДФЛ түләмәскә дә хокуклы. Салым федераль хезмәтендә искәртүләренчә, яңа фатирның мәйданы элеккесеннән зуррак булырга тиеш. Салым хезмәткәрләре балаларның яшенә дә игътибар итәчәк: салым ташламасы гаиләдә балигъ булмаган яисә көндезге бүлектә укучы 24 яшькә кадәр булган балалар яшәгән очракта бирелә.

✓Күпбалалы гаиләләрнең милек һәм җир салымнары буенча өстәмә ташламалары бар. Торакның гомуми мәйданыннан һәр бала өчен биш квадрат метрны алырга кирәк. Мәсәлән, ир белән хатын 70 квадрат метрлы фатирда өч бала белән яши, ди, димәк, салым 55 квадрат метр өчен генә салыначак. Салым кодексының 391 маддәсе нигезендә, күпбалалы гаиләләр җир салымы буенча алты сутыйга «вычет» алырга мөмкин. Мәсәлән, әгәр участок ун сутый булса, салымны дүрт сутый өчен генә түлисе була.

✓Балалары булса, дәүләт хезмәткәрнең салым салыначак керемен киметә. Беренче һәм икенче балаларга булган «вычет» күләме аена 1400 сумны тәшкил итә, өченче һәм аннан соңгы балаларга – 3, сәламәтлеге чикле балага – 12 мең сум. Салым «вычет»ын балигъ булмаган балаларга да рәсмиләштереп була. Икеләтә «вычет» исә опекун, баланы үзе генә үстергән анага яисә атага, баланы уллыкка яисә кызлыкка алган кешегә каралган. Бу ташлама баланы тәрбияләүченең еллык кереме 350 мең сумга җиткәнче бирелә.

✓Салым түләнми торган очракларны да искәртик:
– әгәр дә милек мирас буларак күчсә;
– якын туганы яисә гаилә әгъзасы бүләк итеп бирсә;
– хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә милек саналса;
– бердәнбер торак булса;
– рента килешүе нигезендә кулланылышка күчсә.

pnp.ru

2022 елда Россиядә яшәүчеләр салым «вычет»ы ярдәмендә 2,7 триллион сум акчасын кире кайтара алган. 2021 ел белән чагыштырганда, бу 400 миллиард сумга күбрәк. Халык ипотека, социаль, милек «вычет»ларыннан файдаланган.

Сүзгә-сүз

Алексей СОЗИНОВ, Казан дәүләт медицина университеты ректоры:

Миңа калса, теге яисә бу өлкәгә белгечләр килү-килмәве турында түгел, ә аларны бу өлкәдә «тотып калу» турында уйларга кирәк. Бу – бик зур проблема. Ул хезмәт хакы, социаль шартлар, халыкның медицина хезмәткәрләренә мөнәсәбәтенә дә бәйле.

(«Реальное время» интернет басмасына биргән интервьюдан)

ИЛНЕҢ ТӨП КАЗАНЫШЛАРЫ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән: «Илнең төп казанышлары нәрсә дип саныйсыз?» – дип сорашкан.

11% >> Кырымны кушу
9% >> шәһәрләрне төзекләндерү, юллар ремонты
8% >> авыл хуҗалыгы, сәнәгать өлкәсенең үсеше, машина төзелеше
8% >> икътисад, медицина үсеше, ришвәтчелек белән көрәш
5% >> Кырым күперен төзү, хәрби сәнәгать үсеше, илдә халыкның тормыш сыйфаты яхшыру

Реклама 16+

Сөенечле хәбәр!

2023 елның 5–15 июнь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **444 сум 54 тиен**; гадәти бәясе – ~~512 сум 70~~ тиен

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **1051 сум 80 тиен**; гадәти бәясе – ~~1227 сум 30~~ тиен

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Фәнсез дөнья сансызмы?

Акчага тәгаен дүрт әйберне сатып алып булмый. Мәхәббәтне, сәламәтлекне һәм акыл белән сәләтне. Соңгы ике категорияне Ходай биргән сыйфатлар диярге дә мөмкин. Аларны, булган җәһәттә, җиргә күммәү, үстерү, әрәм-шәрәм итмәү мәслихәт. Чөнки кешелек җәмгыяте, үзенең казанышлары, үсеше дигәндә, зурдан алганда, акыллыларга һәм талант ияләренә бурычлы. Фән, техника, җитештерү хакында сүз йөрткәндә дә шулай. Ул юнәлештә хезмәт куючы галимнәр, конструкторлар, инженерлар – теләсә кайсы илнең байлыгы. Һәрхәлдә, шулай саналырга, булырга тиеш. Фән белән, алдынгы җитештерү белән үзен хөрмәт иткән һәр дәүләт шөгыльләнергә тиешлеге дә бәхәссез.

Өч дистә еллар чамасы элек үк ил җитәкчелегенең Россиягә фән дә, аңа нигезләнгән заманча җитештерү дә ул кадәр кирәкми, дигән карарга килгәнлеген беләбез. Яхшы станокларммы ул, автомобильләрме, самолетлармы – барысын да сатып алып була ич. Өскә яңгыр булып яуган нефть долларларын башкача кая куеп бетермәк кирәк?! Дөнья дигән олы базарда технологияләрне дә сатып алып була. Аларны тудырып мәшәкатьләнәсе булмагач, фән дип, ачышлар дип, ник әле ул кадәр кыбырсырга? Нигә яңадан велосипед уйлап табарга? Туксанынчы еллар уртасында яралган икътисадый доктрина шундыйрак иде.

Андый нияттә бәлки тырнак очы кадәр генә мантыйк та булгандыр. Ни дисәң дә, чикнең теге ягында фән, технологияләр шундый – алар станокларны да, турбиналар, электровозлар, автомобильләрне, күп төрле башка җиһазларны да, бердән, ышанычлы һәм дә заманча итеп ясый, икенчедән, аларның үзкыйммәте, шуңа бәйле сату бәяләре дә шактый арзан. Ә охшаш продукция җитештерә башлау, билгеле брендларга каршы көндәшлек – ифрат та авыр мәрәкә. Чыгымнар да берничә тапкыр артык булачак. 1990 нчы елларда нәкъ шундый караш өстенлек итә дә. Тик… Шул ук җиңел автомобильләрне без чыннан да ясый белмәдек. Көнкүреш электроникасы да бер дә мактанырлык түгел иде. Ә менә авиация сәнәгате һәрдаим алда барды. Тармакка караган фәнни институтлар да яңа, башка беркемдә булмаган технологияләр тудырып торды. Тармак тамырына ник балта чаптык соң? Көндәшлеккә сәләтле башка юнәлешләр дә юк түгел, бар иде. Ә хәзер?

Яңалыклар укыйм. Японнар кояш энергиясен ясалма иярченнәр аша җиргә транспортлауны планлаштыра. Маск дигән кешенең институтлары баш авыруларын нейроимплантлар ярдәмендә дәвалый башлаячак. Галәмгә чыгарылган телескопларның яңа буыны бездән 4 млрд яктылык елы ераклыгында урнашкан галактикаларны фотога төшереп җиргә җибәргән… Үзебездәге яңалыклар тасмасына күз салам. 70–80 процент яңалык фәннән, җитештерүдән ерак торган мәгълүм вакыйгага, аның барышына багышланган.

Шулай да, соңгы ике елны алганда, без кисәк кенә акылыбызга килгәндәй булдык. Илгә инженерлар, техник хезмәткәрләр, тикшеренүләр алып барыр, нәтиҗәгә ирешер яшь, перспективалы галимнәр җитми икән ләбаса. Шул ук юрист, икътисадчы, менеджерларны киләчәк ун, егерме елга җитәрлек итеп әзерләгәнебезне дә соңга калып аңладык кебек. Яшьләрнең аспирантураларга атлыгып тормау сәбәпләренә дә күзебез ачыла башлады. Үз көченә ышанган сәләтле фәнни хезмәткәрнең ни өчен чит илне сайлавына да. Россия Фәннәр академиясенең вице-президенты, Валентин Пармон дигән галим белдерүенчә, соңгы биш елда гына да илдән 50 меңнән артык сәләтле галим киткән. Ник киткән? Чөнки ул тарафларда галим-голәмә өчен менә дигән эшләү һәм яшәү шартлары. Хезмәт хакы да биредәге белән чагыштыра торган түгел. Шуны да әйтик: мондый миграция кире селекциянең иң начары. Сәләтле китә, уртакуллар, уртакулдан түбән торганнар кала. «Мондый күренеш сакланганда ил һичкайчан технологик һәм фәнни суверенитетка ирешә алмаячак», – ди вице-президент.

Ә милләттәшебез, Россия Фәннәр академиясенең (РАН) Океанология институты җитәкчесе, РАН президентлыгына экс-кандидат Роберт Нигъмәтуллин, «НАКАНУНЕ.RU»га биргән интервьюда, бу юнәлештәге мөшкеллекне фәннең ролен ахыргача аңламауда күрә. «Фәннең хаҗәтлеген, Россиянең киләчәге өчен зарурлыгын әледән-әле сөйләп торсалар да, тармакка эчке тулай продуктның (ВВП) барысы 1 процентын гына юнәлтәләр», – ди галим. Европа илләрендә 2,5 процентның норма булуын, Израильдә күрсәткечнең 4,5 процентка җитүен, аерым дәүләтләрдә 5 процентның да чик саналмавын искәртә Нигъмәтуллин.

АКШ дигән илдә әйдәп баручы университетларның бездәге охшаш уку йортлары белән чагыштырганда 8–10 тапкыр күбрәк финанслануы мәгълүм. Нәтиҗә нинди дип уйлыйсыз? Quacquarelli Symonds дип аталган абруйлы инглиз компаниясе ел саен дөнья университетларының рейтингын төзи. Бәяләү критерийлары арасында беренче урында абруй-репутация (төрле илләрдә яшәүче дистә меңнән артык галимнең теге яки бу вуз хакында фикере) һәм дә яшь белгечләргә эш бирүчеләрдән килгән бәяләмә булганын искәртик. Ул рейтинг буенча беренче унлыкта АКШның биш (!) югары уку йорты тора. Илебезнең беренче вузы саналган МГУның рейтингта 78 урында булуы аз гына да куандырмый. «Океан артындагы илдә Нобель премиясе лауреатлары саны ник бездәгедән ун тапкыр күбрәк?» – дигән сорау да риторик булып кала…

Кемдер: «Автор чит-ятларны күтәрә дә, үзе яшәгән илне янә тәнкыйть утына тота, яратмый», – диярге мөмкин. Илне яратам мин. Тик, теләсә нишләтегез, мин аны күземне йомып, башымны иеп, телемне аркылы тешләп ярата алмыйм. Кеше заты үз Ватанын аңлаган, аны бәяләгән, конструктив кимәлдә тәнкыйтьләгән очракта гына илгә файдалы. Сукыр ярату, сукыр патриотизм, тешләнгән тел ил өчен бары зыянга гына. Без илебезне хакыйкать аша, аның җитешсезлекләрен күрсәтеп, алар белән килешмичә яратыйк. Хакыйкатькә мәхәббәт илгә мәхәббәттән көчлерәк булса иде. Илдәге тәртипләрне, аның үткәнен тәнкыйтьләү аңа ялагайланудан, аны алдаудан, килешегез, күпкә яхшырак… Болар – билгеле рус фикер ияләре, язучы, философлары әйткән, фәкыйрегез гомумиләштергән фикерләр.

Без зур, без бөек, без «иң-иң»нәр, без «впереди планеты всей», дия-дия, фәнне, аңа бәйле җитештерүне дә шактый түбәнгә төшердек. Фән – теләсә кайсы илнең киләчәге. Киләчәк булсын дигәндә, безгә бик күп башка юнәлешләргә дә мөнәсәбәтне карап чыгасы, үзгәртәсе түгел микән?

РӘСМИ ТАТАРСТАН

РӘСЕМНӘРДӘ – ИЛ ГАМЕ

«Ярышучы һәм җиңүче буын!» Россия көне алдыннан Казанда «Балалар илне сурәтли» республика бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләгәндә әнә шулай диделәр. Бәйгедә республика шәһәрләреннән һәм районнарыннан 13 мәктәп укучысы җиңде. Яшь рәссамнарны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге Сәркатибе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

tatarstan.ru

– Бу – бик яхшы проект. 17 нче мәртәбә оештырып, шушындый талантлы балаларны күрәбез һәм җиңү белән тәбриклибез. Без моңа зур игътибар бирәбез, чөнки кеше, аның характеры, киләчәге кече яшьтән үк формалаша башлый. Мондый зур конкурсларда катнашу, ярыш рухы балаларга үсәргә ярдәм итә. 10 меңнән артык эш тәкъдим ителгән! Иң яхшы рәсемнәрне сайлап алу бик авыр булгандыр. Бүген нәтиҗә ясап, балаларга һәрьяклап үсүдә зур уңышлар телибез. Сез – ярышучы һәм җиңүче буын. Бу кечкенә җиңүләр, ярышу, талантыгыз һәм осталыгыгыз гомер буе сезнең белән зур тормышка атлаячак, – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Быел балалар рәсемнәрен дүрт темага багышлаган: Россиядә Укытучы һәм остаз елы, Татарстанда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы, традицион тема – юл иминлеге һәм «Мин – патриот».

– Иң яхшы рәсемнәрне сайлап алу, чыннан да, бик кыен булды. Барысын да бүләклисе, һәр баланы билгеләп үтәсе килде, – диде тантанада конкурсның Эксперт советы рәисе Валентина Липужина. – Җылылык, туган илгә, әти-әниләргә карата мәхәббәт хисе балалар рәсемнәрендә шулкадәр ачык чагыла. Без иң яхшыларын сайладык. Сез – җиңүчеләр һәм бүген беренче бүләкләрегезне аласыз. Бу сезнең зур тормыш юлыгызның әле башы гына булсын. Сезнең һәрберегезнең бөек һәм танылган рәссам булуын теләр идек. Алай булмаса да, сездә инде матурлык, Ватанга, әти-әнигә, милли традицияләргә мәхәббәт хисе бар. Ә бу – иң кадерлесе һәм иң мөһиме. Ирешелгәннәрдә генә туктап калмавыгызны телим. Алга таба барыгыз, хыялланыгыз, иҗат итегез, эшләгез. Шул вакытта сезне якты киләчәк көтә.

Ләйсән САФИНА

КӨН-ТӨН УКУ ӘҖЕРЕ

География, әдәбият һәм химия фәннәреннән БДИ нәтиҗәләре игълан ителде. Арада 100 балл туплаучылар да бар. Әгерҗе районының Исәнбай мәктәбе укучысы Камилә Ганиева кайчандыр җене сөймәгән химиядән югары күрсәткечкә ирешкән. Кызык, аны ничек яратырга өйрәнгән икән?



Исәнбай мәктәбенең тарихында моңа кадәр берәүнең дә бердәм дәүләт имтиханнарында 100 балл туплаганы булмаган. Химия укытучысы Энҗе Латыйпованың укучылары арасында 90–95 балл туплаучылар бар. Ә менә абсолют күрсәткечкә ирешкәне – бары Камилә генә. Укытучының хезмәт стажы – 32 ел. Шуның 19 елын әлеге мәктәптә укыта.

– Камилә имтиханнан 100 балл туплагач, бик сөендем. Ни өчен дигәндә, өч еллык хезмәт нәтиҗәсе бу. Авыл мәктәбендә шәһәрнекенә караганда, шартлар да гади, әллә ни шаккатыргыч әйберләр дә юк. Химиядән сәгатьләр саны да аз. Атнага икешәр дәрес укытам. Шуңа күрә өстәмә шөгыльләнергә туры килә. Камилә тәнәфестә дә ял итмәде: вакытын сөйләшеп уздырмады. Бик тырыш, үҗәт кыз. Теш табибы булам дип максат куйды да химия фәненә чумды. Моңарчы бер укучыма да бер теманы 15әр тапкыр аңлатканымны хәтерләмим. Камилә белмәгәнен сорады, барыбер өйрәнәм, диде. Мондый укучылар күбрәк булсын иде әле. Дөрес, башта аңа бик авыр иде. Мәктәптән елап та кайтып киткәләде. Тик бирешмәде, тырышлыгы белән кыенлыкларны җиңә алды, – ди Энҗе Латыйпова.

Камилә уку белән генә мавыгып, бар дөньясын оныткан дип уйламагыз тагын. Юк, алай түгел. Бәйләргә дә оста ул. Өйләрендәге чебешләрне дә ул тәрбияли. Тавыкларның йомыркаларын җыярга ярата икән. «Чебиләрнең үскәнен, алардагы үзгәрешләрне күзәтү кызык миңа. 9–10 сыйныфларда укырга иртән сыер савып китә идем. 11 сыйныфта БДИга әзерләнеп, бу эшкә вакыт калмады шул», – ди. Әтисе Девятернә авылы җирлеге башлыгы булса да, иркә кыз түгел, димәк.

Үзе 100 балл туплармын дип башына да китермәгән. Ә менә күршеләре бер дә шикләнмәгән. Ганиевларның тәрәзәсендә утның ел буе төнге сәгать 2гә кадәр сүнмәгәнен беләбит алар. Камилә үзе дә имтиханга әзерләнү өчен бик күп көч түгәргә туры килүен әйтә. Башта мәктәптә – укытучысы белән, аннан өенә кайткач, онлайн мәктәптә шөгыльләнгән. Ай ахырына 400әр бирем эшләгән. Өстәвенә китаплар укыган, интернеттан эзләнгән. Моның кадәр тырышып та, сынауны начар баллга бирергә ярый димени?

– Моңарчы 100 балл туплаучыларны бик акыллы кешеләр дип саный идем. Хәзер фикерем үзгәрде. Ни өчен дигәндә, үзем – бик гади укучы. Тырышлыгым белән алдырдым. Мәктәптә «4–5ле» билгеләренә укыдым. Мине бервакытта да «ботаник» дип йөртмәделәр, – дип елмая ул. – Имтихан нәтиҗәсен белгәч, шатлыгымнан күккә очып киткәндәй булдым. Әтием, әнием дә бик сөенде. Миңа ышанганнары өчен рәхмәт. Укытучымның да тырышлыгын онытмам.

Камилә дә, башкалар кебек, БДИдан курыккан. Ни дисәң дә, киләчәк язмышын билгели бит ул. Аның да вузга укырга керәсе бар. Шуңа күрә яхшы күрсәткечләр кирәк.

– Бик зур сынау бу. Тырышып та, баллары аз булуны кайберәүләр психологик яктан бик авыр кичерергә мөмкин. Имтиханнарны алдан бирәп карагач, камераларга ияләшкән идек инде. Минемчә, БДИ кирәк, аннан баш тартырга ярамый. Әлеге сынауны тапшырып, илнең теләсә кайсы вузына кереп була чөнки. Мин исә Казан, Ижаудагы югары уку йортларын сайларга җыенам. Кайда БДИ баллы җитә инде. Әлегә биология фәнен бирәсем бар. Рус теленнән исә нәтиҗә көтәм. Яхшыга өметләнәм, – ди Камилә.

– Мәктәп системасында нәрсәне үзгәртер идең? – дип тә сорадык аннан.

– 11 нче сыйныфта кирәкмәгән фәннәр шактый. Без аларны 10 сыйныфка кадәр укыдык бит инде. Соңгы елны бары темаларны гына кабатлыйбыз. Шуңа күрә нигә укучының кадерле вакытын алырга? Вузга кергәндә кирәкле фәннәрне яхшылап өйрәнү отышлырак булачак, – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

КЫЙММӘТЛЕ ЮЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сабыр итегез! Казан халкы һәм башкалада яшәүчеләргә бу җәйдә түземлек бик тә кирәк булачак. Бу көннәрдә үк шәһәрнең ике зур юлын – «Миллениум» күперен һәм Уң як Болак урамын өлешчә ябачаклар. ЮХИДИ хезмәткәрләре исә республика юлларындагы ремонт эшләре турында кисәткән. Кайсы урыннарны читләтеп узуың хәерлерәк?

Машина йөртүчеләр һәм җәяүлеләргә башкала урамнарындагы уңайсызлыкларга әзер торырга киңәш иттеләр. Шәһәрдә юлларны тәртипкә китерү эшенә керешәчәкләр. Бу хакта «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Искәндәр Гыйниятуллин кисәтте. «Миллениум» күперенең бер як полосасы, мәсәлән, киләсе дүшәмбедән тулысынча ябылачак. Фатих Әмирхан урамыннан Вишневский урамына бара торган юлга «кирпеч» эләчәкләр.

– Күпернең гомуми озынлыгы 1524 чакрым тәшкил итә. Хәзерге вакытта биредә тәүлегенә 50 меңнән артык машина уза. Уналты ел элек ачылган «Миллениум»да моңарчы бер тапкыр да капиталь ремонт үткәрелмәде. Ремонт вакытында машиналар күпернең икенче ягыннан хәрәкәт итәчәк. Моның өчен биредә хәзерге өч полоса урынына ике як-якка вакытлыча икешәр юл тамгасы салачаклар, – дип сөйләде башкаланың Транспорт буенча комитеты җитәкчесе урынбасары Марат Шәрипов.

Казанның аерылгысыз өлешенә әверелгән күпергә ремонт кирәклеген бу юлдан бер тапкыр гына үтеп караучылар да чамалый анысы. «Халык контроле»нә килеп ирешкән шикаятьләр арасында «Миллениум» бик еш телгә алына. Берәүләр күпердәге чокыр-чакырлардан зарланса, икенчеләр «буразна»лы юлдан туйган. Халыкны ишеткәннәр булса кирәк.

– Күпер яңадан кайчан ачылачак? – дип тә кызыксынды журналистлар Марат Шәриповтан.

Аның әйтүенчә, иң элек күперне тикшерергә һәм башкарылачак эш күләмен билгеләргә кирәк. Ремонт кайчан бетәчәге шуннан соң гына билгеле булачак.

Уң як Болак урамындагы төзекләндерү эшләре исә бу урыннан узучы магистраль җылы үткәргечне алмаштыру зарурлыгына бәйле.

– Әлеге җылы үткәргечнең куллану вакыты чыккан. Соңгы елларда гына да бу торбага бәйле 18 гадәттән тыш хәл очрагы теркәлгән. Эш барышында искесе урынына зуррак торба куелачак. Бу шәһәрнең үзәк өлешен алга таба үстерү мөмкинлеген тәэмин итәчәк, – диде Искәндәр Гыйниятуллин.

Рәсми мәгълүматларга караганда, тузган җылы үткәргеч 62 торак йорт, 10 кунакханә, 4 мәктәп, 4 медицина оешмасы, 3 балалар бакчасы һәм тагын 700гә якын кибет, кафе, ресторан ише кулланучыларга хезмәт күрсәтә. Аны 1976 елда ук салган булганнар. Уң як Болак буйлап ялларда тәүлегенә 24 меңнән артык машина уза. Ремонт эшләре бу ялларда башланып, 31 августка кадәр дәвам итәчәк дип көтелә.

– Юлчылар тәүлек буе эшләячәк. Әлеге урамда торак йортлар күп булуын исәпкә алып, төнлә бик тавышланмаска тырышачакбыз. Шунысы да бар: Уң як Болак тулысынча ябылмый, тәүлек вакытына һәм машиналар күплегенә карап, аны өлешчә ябып торачакбыз. Ничек кенә булмасын, хәрәкәт итү кыенлашачак, – диделәр матбугат очрашуында.

Сан

2023 елда Татарстанда юл эшләренә, барлык зур проектларны да исәпкә алып, **250** миллиард сум акча тотылачак дип фаразлана.

ЮХИДИ инспекторлары исә федераль һәм республика юлларындагы ремонт эшләре турында кисәткән. Татарстан Дәүләт автоинспекциясенең матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, бүген федераль автомобиль юлларының 26 участогында юлчылар эшли. Тәгаен әйткәндә, «М7» трассасының – 15, Казан – Оренбург юлының – 8, «М5» юлының – 2 һәм Цивильск – Ульян юлының 1 өлешендә, ремонт булу сәбәпле, аеруча сак булырга кирәк. Республика дәрәҗәсендәге юлларны да тәртипкә китерәләр. Хәзерге вакытта шундый 32 мәйданда эш бара. Татарстанның Алабуга, Арча, Әтнә, Балык Бистәсе, Биектау, Буа, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Саба, Теләче, Тәтеш, Чирмешән, Чистай, Чүпрәле һәм Ютазы районнарындагы юлларның аерым өлешләрен төзекләндерәләр. Мәсәлән, Әтнәдә Олы Әтнә – Чыпчык юлының тузган урыннарын рәткә китерәчәкләр. Чүпрәледә Иске Чүпрәле – Татар Шатрашаны – Городище юлында юлчылар эшли. Лениногорск районына керүче Чаллы – Сарман юлы да ялт итәчәк дип көтелә. Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, соңгысында дүрт мәйданда эшләр алып барылачак. Алты чакрым озынлыктагы юлны төзекләндерү өчен республика бюджетыннан 190 миллион сумга якын акча бүлеп биреләчәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

КҮҢЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ – КАРТАДА

РЕСПУБЛИКА ОСТА КУЛЛАРЫ ТАТАРСТАННЫ ЧИГҮГӘ ТӨШЕРӘ

Татар кызлары элек-электән үз иткән чигү сәнгате соңгы елларда онытыла башлады. Инде хәзер Сабан туена атап сөлге, кулъяулык чигүчеләр дә юк диярлек. Менә шушы онытылган сәнгатьне кире кайтарырга, булган осталарны барларга кирәк дип санаучылар бер кызыклы проект игълан итте.

«Татарстан Республикасының чигүле картасы» дип атала ул һәм Татарстанда дус-тату яшәүче милләтләрне берләштерү, һөнәрче-осталарга ярдәм итү, милли чигүле эшләнмәләрне популярлаштыру кебек максатларны колачлый. Аны Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында республиканың Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр Советы», Татар мәдәни ресурс үзәге оештырды.

«Татарстан Республикасының чигүле картасы» проекты нидән гыйбарәт булуын болай да чамалыйсыздыр. Чигү белән шөгыльләнүче оста куллар үзләренең төбәкләрен чагылдыра торган фрагментлар тәкъдим итәчәк. Һәр районның горурланып сөйли торган урыннары, шәхесләре, тәм-томнары, эшләнмәләре, символлары була бит. Оештыручылар менә шул үзенчәлекле элементларны берләштерергә ярдәм итсә, осталар аны чигүгә төшерә. Нәтиҗәдә республиканың 45 районыннан җыелган 45 фрагменттан, нәкъ җырдагыча, асыл һәм ефәк җепләр белән чигелгән Татарстан картасы килеп чыгачак. Аны безгә 30 август – Республика көнендә күрсәтергә вәгъдә итәләр. Соңыннан әлеге карта Татарстанның Милли музеенда урнаштырылачак.

– Һәр районның чиге бар. Бу чигелгән картада да яхшы күренәчәк. Осталар район үзенчәлекләрен генә түгел, ул районга хас төсләрне, орнаментларны да исәпкә алачак. Әйтик, әгәр районда күпләп чуашлар яшәсә, ул чуаш орнаменты булырга мөмкин. Бернинди чикләүләр юк, иң мөһиме – һәр районга үзен күрсәтергә мөмкинлек бирү, – дигән иде проект турында Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова.

Иң җитез осталар Чистайда икән. Чөнки иң беренче булып үз картасын нәкъ менә шушы район тәкъдим иткән. Гомумән, оста куллар сөенә-сөенә катнашкан бу проектта. Уңганлыкларын күрсәтү өчен бер мөмкинлек бит. Арча районы картасын чиккән Алия Фаздалова шулай ди.

Алия Фаздалова чиккән Арча картасы.

– Рәсемен Арча сәнгать мәктәбе укытучысы ясап бирде. Ә чигүне өч төрле техника кулланып башкардым: келәм чигүе, тамбурлы чигү һәм тоташтан чигү. Бу техникалар юкка гына сайланмады. Арча музеендагы чигү эшләнмәләрен өйрәнгәннән соң, нәкъ менә шуларга тукталырга булдык. Үзем келәм чигү белән шөгыльләнгәч, бик рәхәтләнеп, бик теләп катнаштым проектта. Картадагы һәр элемент Арча турында сөйли, һәр элементка аерым мәгънә салынган, – дип сөйләде ул безгә.

Әлки картасын район мәдәният йортында костюмнар бүлеге мөдире Сөембикә Хәмитова чиккән. Чигелгән картада районда яшәүче халыкларның – чуаш һәм татарларның милли бизәкләре һәм символлары да төшерелгән. Әйтик, лалә чәчәге ул – яңарыш һәм татарларның кунакчыллыгы билгесе. Кырлардан баручы дөяләр кайчандыр Әлки төбәгендә бөек сәүдә юлы узуы турында сөйли икән.

Югары Ослан районының чигелгән картасына күз салсаң, анда яшәүчеләрнең балык тотарга яратуын, алай гына да түгел, районның төп шөгыле шул булуын күрәсең. Югары Ослан районы балыкчылар, капитаннар династияләре белән дан тота бит. Картаны чиккән оста кызлар – Татьяна Тюрина, Анастасия Еремеева, Ксения Анохина да шуны чагылдырырга тырышкан.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «АйСиЭл-КПО ВС» акционерлык җәмгыятенең музей директоры **Бәдретдинова** Маргарита Шәмсетдин кызы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Дуслык ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты» муниципаль казна учреждениесе бүлеге Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе киңәшчесе **Фәттахов** Ирек Тәлгать улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүләре өчен Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге башлыгы **Гобәев** Әсхәт Минзаһит улы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының бюджет бүлеге башлыгы **Дәүлиева** Минсәрия Миңнегали кызы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге башлыгы **Зарипов** Илсур Гарифулла улы, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре **Мөхәммәтҗанова** Гөлнара Илгизәр кызы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Бөрешле авыл җирлеге башлыгы **Смирнова** Лидия Алексеевна, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча ярдәмчесе **Урысова** Валентина Исаковна, Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе баш киңәшчесе **Латыйпов** Айрат Камил улы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республикада җирле үзидарәне үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге башлыгы **Гайнуллин** Данияр Сәгыйть улы; республикада дәүләт кадастр исәбен алу системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле хезмәте өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе оештыру һәм контроль бүлеге башлыгы **Галиуллина** Галина Владимировна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Эталон-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Әхтәмов** Рөстәм Баязит улына, «Аксу-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте агрономы (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Кәлимуллин** Рафис Зәкиулла улына, «Авзалов Алмаз Нияз улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы агрономы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Нигъмәтуллин** Миңнерәшит Роверт улына **«Татарстан Республикасының атказанган агрономы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенең серология бүлеге башлыгы урынбасары – ветеринария табибы **Аллегораки** Елена Николаевнага, «Теләче районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Гарипов** Илгизәр Габделмәүлет улына, Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесенең паразитология бүлеге башлыгы – ветеринария табибы **Зубкова** Людмила Александровнага **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Агро Л» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте зоотехнигы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Хәлиуллин** Альберт Азат улына, «АЛГА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте зоотехнигы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Хәсәнов** Илгиз Уйдат улына **«Татарстан Республикасының атказанган зоотехнигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Чистай» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Чистай районы) **Габетдинов** Рамил Равил улына, шәхси эшкуар, «Нуретдинов Рафил Гыйлемнур улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Григорьев** Юрий Алексеевичка, «ЗАРЯ» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы механизаторы (Татарстан Республикасының Арча районы) **Закирҗанов** Рәфхәт Рифат улына, «Агро Актив» авыл хуҗалыгы предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Апас районы) **Җәләлиев** Фәрдис Миңнулла улына, «Чүпрәле Таң Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Пайзе** Николай Васильевичка, «Эталон-Агро» җаваплылыгы. чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы механизаторы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Сәйдәшев** Рифкать Исмәгыйль улына, «Аксу Агро» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Аксубай районы) **Шишкин** Юрий Сергеевичка, «Кичүчат» авыл хуҗалыгы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Әлмәт районы) **Яруллин** Дамир Минсәгыйть улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ОРСИС-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең гомуми җитәкчелеге терлекләрне тукландыру һәм үрчетү буенча генераль директоры урынбасары (Татарстан Республикасының Түбән Кама районы) **Нурхәмәтова** Татьяна Васильевнага, «Тукай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Әтнә районы) **Хәкимов** Илфат Рәфкать улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәренең Идел буе район суды рәисе урынбасары **Корбанова** Римма Борһан кызына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Балтач һәм Кукмара районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы **Шакирова** Рәсимә Габдрәшит кызына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык дүртенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык дүртенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрнең хәле һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
3. «2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 422-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «2022 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 421-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 425-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 429-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 424-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» һәм «Приволжский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 420-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 431-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 430-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 419-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында дәүләт мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләр турында» 427-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану хакында» 423-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 426-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 390-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 428-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11^1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 434-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 432-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
19. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларының (карарлар нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында.
20. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында.
21. Экологик хисаплылык тапшыру өлкәсендә таләпләрне камилләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында.
22. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составында үзгәреш турында.
23. 2022 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында хисап.
24. А.Н. Латышев турында.
25. «Республика Татарстан» газетасы баш мөхәррире вазыйфасына А.Е. Угаровны билгеләп кую турында.
26. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 145 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Саха Республикасы (Якутия) Дәүләт Собраниесе (Ил Төмән) закон чыгару инициативасы хакында.
27. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{10} статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Удмурт Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы хакында.
28. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 353469-8 номерлы федераль закон проекты турында (кулланучыга товарларның (продукциянең) техник регламентларда билгеләнгән таләпләргә һәм (яисә) мәҗбүри таләпләргә туры килүе турында тапшырылган туры килү сертификатлары һәм теркәлгән декларацияләр реестрындагы язмага сылтама бирү хакында).
29. «Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» Россия Федерациясе Законының 52 статьясына үзгәреш кертү хакында» 325561-8 номерлы федераль закон проекты турында (түләүле чаралар оештырганда мәдәният оешмалары ташламалар билгеләргә хокуклы аерым категория гражданнарның исемлеген тулыландыру өлешендә).
30. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 369931-8 номерлы федераль закон проекты хакында (салым сәясәтенең төп юнәлешләре аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру өлешендә).
31. «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 346646-8 номерлы федераль закон проекты хакында (мөлкәти ярдәм чараларын үзмәшгуль гражданнарга күрсәтү өлешендә).
32. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 8 июне
№ 1976-VI ДС

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп өч елга түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Әлмәт суд районы буенча:
5 нче суд участогына – Сәлахетдинов Рөстәм Ришат улын;
Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча:
7 нче суд участогына – Маннанова Айгөл Әхнәф кызын;
Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Киров суд районы буенча:
4 нче суд участогына – Биктимерова Миләүшә Закирҗан кызын;
Татарстан Республикасы Минзәлә суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Абызова Мария Ивановнаны;
Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:
1 нче суд участогына – Миндубаев Эдуард Рамил улын;
Татарстан Республикасы Тукай суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Гыйздәтуллин Аяз Наил улын;
Татарстан Республикасы Чистай суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Тякмаев Александр Владимировичны.

2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләр чоры чикләнмәгән вакытка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Бөгелмә суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Ефремова Елена Геннадиевнаны;
Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:
2 нче суд участогына – Батыршина Асия Фазылҗан кызын;
Татарстан Республикасы Түбән Кама суд районы буенча:
10 нчы суд участогына – Җәләев Роберт Ренат улын;
Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Совет суд районы буенча:
6 нчы суд участогына – Шумунова Роза Вячеславовнаны.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә сайланган Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының вәкаләтләр чоры алдагы вәкаләтләр чоры тәмамланган көннән башлана.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 8 июне
№ 1977-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ:**

1. «Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе турында» 2005 елның 26 маендагы 1292-III ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 5; 2009, № 5; 2012, № 2, № 4, № 6 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (XI өлеш); 2018, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

Фазлыева Ләйлә Ринат кызы – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе (килешү буенча);

Кадыйров Рөстәм Раиф улы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;

Яһудин Шакир Шәяхмәт улы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе, комиссия рәисе урынбасары;

Анфимова Алла Леонидовна – Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары (килешү буенча);

Әхмәтшин Альберт Мәхмүт улы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенең хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек секторы баш киңәшчесе (килешү буенча);

Бутаева Наталья Владимировна – Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары (килешү буенча);

Вәлиев Рамил Миргасыйм улы – «Хәтер китабы» редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе баш мөхәррире (килешү буенча);

Габдрахманова Гөлнара Зәкәрия кызы – Архив эше буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисе (килешү буенча);

Завгороднев Алексей Анатольевич – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары (килешү буенча);

Җәләлиева Әминә Гәрәй кызы – Татарстан Республикасы пенсионерларның һәм инвалидларның – сәяси репрессияләр корбаннарының региональ иҗтимагый-гуманитар оешмасы рәисе (килешү буенча);

Захарова Светлана Михайловна – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе;

Ибәтов Мөхәррәм Мансур улы – Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары (килешү буенча);

Нәбиев Ринат Әхмәтгали улы – тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры (килешү буенча);

Сабурская Сәрия Харис кызы – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча);

Таһиров Индус Ризак улы – тарих фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтының Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе бүлегенең ватан тарихы кафедрасы профессоры (килешү буенча);

Хвостиков Игорь Владимирович – Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча);

Шакиров Илнур Ирек улы – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы (килешү буенча).»;

2) кушымтаның 1 бүлегендәге икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасы законнары җыелмасын чыгару буенча республика комиссиясе төзү турында» 2009 елның 5 ноябрендәге 478-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 11; 2012, № 9; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4; 2017, № 11) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы законнары җыелмасын чыгару буенча республика комиссиясе составыннан (алга таба әлеге пунктта – комиссия) А.Б. Гревцовны, В.Н. Демидовны, Б.Л. Железновны, Ф.Г. Хөснетдиновны чыгарырга;

2) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Долгов Марат Шамил улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Скирда Максим Владимировичны – Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын (килешү буенча);

3) комиссия рәисе урынбасары Сәфәров Әсгать Әхмәт улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе җитәкчесе – комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

4) комиссия әгъзасы Глухова Лариса Юрьевна вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 8 июне
№ 2011-VI ДС

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫНДА

Җир шарында гаҗәеп һәм шаккаткыч нәрсәләрнең берсе – кыргый хайваннар дөньясы. Алар турында кайсыгыз күбрәк белә икән?

1 Нинди ерткыч хайванның тәне авырлыгына карата йөрәге бик кечкенә санала?
а) леопард;
б) бүре;
в) арыслан.

2 Зур фил бер тәүлеккә күпме су эчә?
а) 15–50 л;
б) 100 литрдан артык;
в) 80 л.

3 Кызыл китапка кертелгән хайваннар төркемен табыгыз.
а) үрдәк, аккош, торна;
б) селәүсен, төлке, соры аю;
в) бөркет, фламинго, уссурий юлбарысы.

4 Санап үтелгән хайваннарның кайсы җир-су хайваны түгел?
а) тритон;
б) бака;
в) крокодил.

5 Кайсы хайваннар үлән ашаучы?
а) сыер, бегемот, жираф;
б) бүре, төлке, кабан;
в) поши, тюлень, кит.

6 Кайсы туклану чылбыры дөрес?
а) нарат – тукран – кайры коңгызы;
б) арыш – тычкан – елан – бөркет;
в) лайлач – кәбестә – бака.

Җаваплар: 1) в; 2) б; 3) в; 4) а; 5) а; 6) б.

Гаҗәеп дөнья

Минем Җир шарын гел чәчәкле, күбәләкле итеп күрәсем килә. Карагыз, нинди матур бит ул!
Әминә ГАЛИӘСКӘРОВА, 6 яшь. Питрәч районы Шәле авылы

Мин, үскәч, табигать сакчысы булырга телим. Табигать – безнең туган йортыбыз. Аны саклап тормасак, ул пычраначак. Безнең сәламәтлегебезгә зыян киләчәк. Әйләнә-тирәбезне саклыйк, елга-күлләрне чиста тотыйк!
Мөслим ГАЗИЗУЛЛИН, 6 яшь. Питрәч районы

Газетаның киләсе саны 14 июньдә чыга.

ДИЛӘРӘ СӘЛАХИЕВА:

«СӘХНӘДӘ СИН ҺӘМ ГЕРОЕҢ ГЫНА БАР»

Йөзендә елмаю балкый, ә күзләре очкынланып яна. Сәхнәдә булганда бар дөньясын онытып, бөтен күңелен биреп уйный. Сүзебез – мәктәп театр коллективларының «Сәйяр» шәһәр фестивалендә «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңгән яшь артист Диләрә СӘЛАХИЕВА турында. Һәр яктан тырыш, уңган кыз белән кызлар гимназиясендә уку үзенчәлекләре, сәхнә тормышы һәм киләчәккә планнар турында сөйләштек.

:: Диләрә, синең иҗат юлың ничек башланды?
– Иҗат белән мин бәләкәй чактан ук шөгыльләнәм. Беренче сыйныфтан ук төрле чараларда катнашам, шигырьләр сөйлим, мәктәптә узган чараларны алып барам. Фортепиано буенча музыка мәктәбен тәмамладым, вокал белән шөгыльләндем. Киләчәк тормышымны да иҗат белән бәйлисем килә.

:: Кызлар гына булган гимназиядә уку ничегрәк ул?
– Гимназия безнең өй янында гына. Аның тарихы халык язучысы, драматург Туфан Миңнуллин исеме белән турыдан-туры бәйле. Өр-яңа, шундый яхшы мәктәп салдырып калдырганы өчен шулхәтле рәхмәтле без аңа. Аны минем күз алдында төзеделәр. Гимназиядә тулы, вакыйгаларга бай тормыш белән яшибез. Бездә 400дән артык кыз бала укый. Гимназиябездә тыныч, рәхәт атмосфера хөкем сөрә.

:: Мәгърифәтче, татар кызларын белемле итү өчен бөтен көчен куйган Фатиха Аитова исемендәге гимназиядә уку зур җаваплылык та, килешәсеңдер?
– Әлбәттә. Гимназия татар кызларын тәрбияләүнең иң яхшы традицияләрен дәвам итә. Бездә барлык чаралар татар телендә алып барыла. Татар булуым, татар телендә сөйләшүем белән бик горурланам мин. Кая барсак та, рәхәтләнеп үз телебездә аралаша алабыз.

:: Иҗатка кире әйләнеп кайтыйк. Син быел мәктәп театр коллективларының «Сәйяр» шәһәр фестивалендә «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңүче булып танылдың. Театр дөньясында кайнау ошыймы сиңа?
– Үзебезнең гимназиядәге «Хәят» театр студиясенә 7 нче ел йөрим. Аны яшәткәне өчен директорыбыз Зөммәрәт Шамил кызы Нәгыймовага бик зур рәхмәт! Укытучыбыз – Галиәсгар Камал театры артисты, Татарстанның атказанган артисты Алмаз абый Сабирҗанов. Дәресләребез бик күңелле уза. Без төрле уеннар уйныйбыз, тренинглар узабыз. Һәр елны бер яңа спектакль куябыз. Һәм һәр елны диярлек шәһәр буенча да, республика конкурсларында да гран-при алып киләбез. Быел без Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» әсәрен сәхнәләштердек. Бу – татар дөньясында иң беренче куелган әсәр икән. Спектакльдә мин төп герой Бичара кыз – Маһитапны уйнадым. Шул роль белән «Сәйяр» шәһәр фестивалендә «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңдем. Театр студиясе 100 мең сум премия белән бүләкләнде.

:: Ә үзеңне киләчәктә сәхнәдә күрәсеңме?
– 7 ел театр түгәрәгенә йөрү миңа бик зур тәҗрибә, үсеш бирде. Рольләр башкару бик җаваплы эш. Аңа бик нык әзерләнергә кирәк. Сәхнәдә булганда син бөтен проблемаларыңны, уйларыңны онытып торырга тиеш. Анда син һәм героең гына бар. Берничә тапкыр спектакль куйганда авырып, температуралы килеш сәхнәгә чыгарга туры килде. Шул чакта мин артист хезмәтенең нинди авыр һәм җаваплы икәнен аңладым.

:: Тагынниләр белән кызыксынасың?
– Олимпиадаларда, төрле конференцияләрдә, театр фестивальләрендә, шигырь конкурсларында катнашам. Әйтик, быел рус теле һәм әдәбиятыннан республика олимпиадасында призлы урын яуладым. Сыйныфыбыз белән КФУның Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтына укырга йөри башладык. Анда без психологик-педагогик курста укыйбыз. Уку нәтиҗәләре буенча мин «Ел укучысы» булып танылдым. Шулай ук «Талантлар университеты»нда медиакоммуникация буенча курслар уздым. Миңа анда уку бик ошады. Бәлки, киләчәктә шул юлдан китәрмен дигән уйлар да бар. Эш урыным иҗатка бәйле булсын иде.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Кунагыбыз турында белешмә

- Диләрәгә – 16 яшь;
- Казанның Фатиха Аитова исемендәге 12 нче татар кызлар гимназиясенең 10 нчы сыйныфында укый;
- фортепиано, укулеледа уйный, театр түгәрәгенә йөри;
- җырларга, китаплар укырга ярата.

«Акыллы балалар белән эшлим»

«Безнең аша үткән балалар тәрбияви һәм рухи яктан үсә». 20 елга якын балалар хоры дирижеры булып эшләүче Эльвира Төхвәтуллина әнә шулай ди. Республиканың төп музыкаль вузы – Казан консерваториясендә инде күп еллар хезмәт куючы дирижер белән әңгәмә кордык.

Эльвира Төхвәтуллина Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган. Ул – хор белән дирижерлык итү кафедрасына нигез салучы Семен Казачковның укучысы.

Эльвира Төхвәтуллина Казанның 13 нче номерлы балалар музыка мәктәбендә укыта. Кече, урта һәм өлкән хорларны җитәкли. Ул җитәкләгән «Аллегро» концерт хоры шәһәр чараларының аерылгысыз катнашучысы булып тора. Ел саен үткәрелә торган татар хор музыкасы фестивалендә дә актив катнашалар икән. Сүз уңаеннан, быел ул Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында узды.

– Быел фестиваль Габдулла Тукай иҗатына багышланды. Без хәзерге заман композиторлары музыкасын, татар опералрыннан, мюзиклларден, драма спектакльләреннән өзекләр башкардык. Шулай ук быел безнең өчен бик кызыклы һәм истәлекле вакыйга булды. Мәскәүгә гастрольләргә, «Звучит Москва» халыкара музыка фестиваленә бардык. Анда сольный концертлар куйдык. Әлбәттә, мин татар музыкасына йөз тоттым. Икенче дәрәҗә лауреат булып, көмеш медаль алып кайттык.

Классик музыка – рухи тынычлык бирә торган һәм кешене баета торган бердәнбер музыка, дип саный тәҗрибәле дирижер.

– Минем куллар аша үткән балалар тәрбияви һәм рухи яктан үсә. Без җырлап кына калмыйбыз, композиторлар, музыка юнәлешләре турында сөйләшәбез, шигърият дөньясына чумабыз, – ди Эльвира Төхвәтуллина. – Классик һәм заманча композиторлар музыкасын башкарабыз. Һәм, әлбәттә, репертуарыбызның аерылгысыз өлеше – татар композиторлары музыкасы, халык җырлары. Нәҗип Җиһанов, Салих Сәйдәшев, Рәшит Абдуллин, Шамил Шәрифуллин музыкасын, шагыйрьләребез Габдулла Тукай, Муса Җәлил шигырьләренә язылган җырларны балалар яратып башкара. Мин аларда музыка аша туган телгә мәхәббәт тәрбияләргә тырышам.

Эльвира Төхвәтуллинаның шәкерте, 7 нче сыйныф укучысы Әлмирә Сәгыйрова «Аллегро»-ның өлкән хорында шөгыльләнә.

– Минем өчен музыка – бик кызыклы, мавыктыргыч дөнья. Без мәктәп чараларында, Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында еш чыгыш ясыйбыз. Күптән түгел Мәскәүгә бардык. Миңа андагы концерт заллары бик ошады. Аларда акустика бик яхшы, – ди Әлмирә. – Мине музыка илһамландыра. Үзем дә кыска көй яза алам. Укытучыбыз төрле композиторлар белән иҗади очрашулар уздыра. Бу безнең өчен бик кызыклы һәм кыйммәтле. Мондый очрашулар белем дәрәҗәсен арттыра, дөньяга карашны киңәйтә.

ВИТАМИНЛЫ ҖӘЙ

Җәйнең иң тәмле һәм көттереп килә торган вакыты җитте. Урманда да, бакчада да җиләкләр пешә. Кояшлы, эссе көннәр торганда, организмга җиңел һәм тәмле ризыклар кирәк. Витаминнарга бай һәм энергия өсти торган сезонлы яшелчә, җиләк-җимешләрне барладык.

БАКЧА ҖИЛӘГЕ (виктория)
Бакча җиләге – С витаминына иң бай җимешләрнең берсе, аның 100 граммында көнлек норма бар. Бакча җиләге үзе дә, аның яфраклары да матдәләр алмашын һәм кан басымын нормальләштерә, йокысызлыктан булыша. Составында бик күп минераллар булганга күрә, ул организмны чистарта һәм картаю процессын акрынайта. Бакча җиләге авитаминоз, кан басымы авыруларын, подагра, атеросклероз кебек авырулардан да менә дигән дәвалану чарасы булып тора!

КАРЛЫГАН
Кара карлыган – калийның иң бай чыганагы. Кан басымы күтәрелүдән бер дигән дәва. Бу җимешне йогыртка кушсагыз, калий һәм кальцийга бай ризык килеп чыгачак. Теш казналары авыртудан, ларингит яки бронхит кебек сырхаулардан да кара карлыган ярдәмгә киләчәк.
Кызыл карлыган организмнан шлакларны чыгаручы пектиннарны берләштерә. 100 грамм кызыл карлыган – көндәлек кирәкле С витамины чыганагы. Пешереп ашаганда да составында тимер, калий һәм тиз үзләштерелүче клетчаткалар саклана.

ЧИЯ
Чия ялкынсынуны баса, кандагы шикәрне «көйли». Чия составында антоциан һәм биофлавоноидлар бар икән. Болары исә артрит һәм баш авыртуларына каршы көрәшә. Ә төче чиядә (черешня) матдәләр алмашы процесслары өчен мөһим булган калий күп. Шулай ук тимер бар, ул анемияне җиңәргә ярдәм итә. Төче чиядә көчле ютәлне дәваларга, астма симптомнарын басарга һәм сулыш алуны иркенәйтергә булышучы В витамины да күп.

АЛМА
Алмадагы файдалы элементлар баш мие эшчәнлегенә уңай йогынты ясый, уйлау сәләтен һәм хәтерне яхшырта. Шуңа күрә имтиханнар чорында күп итеп алма ашарга киңәш ителә. Алмада булган B_1 витамины арыганлык, күңел төшенкелеге, йокысызлык белән көрәшергә ярдәм итә.

КУРА ҖИЛӘГЕ
Өлгереп җиткән кура җиләгендә файдалы матдәләр һәм витаминнар, органик кислота, пектин, В һәм С витаминнары күп. Җиләк антиоксидантларга бай булуы нәтиҗәсендә баш мие эшчәнлеген яхшырта һәм канда шикәр микъдарын көйли. Җиләкне әз-әзләп, әмма даими ашау йөрәк өчен бик файдалы. Кура җиләге А витаминына да бай, ул күз күрүен яхшырта, тиренең картаю процессын әкренәйтә. Организм яхшырак эшкәртсен өчен аны эремчек яки каймак белән ашарга киңәш ителә.

АБРИКОС
Ул сусыл, татлы тәме белән генә түгел, организм өчен кирәкле микроэлементларга бай булуы белән дә файдалы. Әлеге кызгылт-сары җимеш – төрле авырулардан дәва. Составында калий күп, шуңа да абрикос кан тамырлары өчен файдалы. Магний, В витаминына бай булу сәбәпле, ул нервларны тынычландыра, баш авырту, арыганлык, депрессия вакытында хәлне җиңеләйтә. Вируслы авырулар чорында иммунитетны ныгыту максатыннан да абрикос ашагыз.

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 282

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+